ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәпь урамы, 17
йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 ел 31 нче гыйнвар № 5

**Акбаш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында гражданнар җыенының 31 октябрь 2022 ел, №1,карарын тормышка ашыру максатларында, Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Акбаш авыл җирлеге гражданнарының кушымта итеп бирелгән үзара салым акчасы җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендына, Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм http:pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырырга .
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы: Л.Р.Сөнәгәтуллина

Кушымта 1
Акбаш авыл җирлеге Башкарма
комитеты карарына
2023 елның 31 гыйнвары , № 5

**Акбаш авыл җирлегенең гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Акбаш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары Акбаш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган гражданнарның гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2023 елның 1 февраленнән 25 мартына кадәр срокта түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаек сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт булмау,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә, өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерүнамә) бланкы мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук кул кую яки почта элемтәсе чарасына юллау юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Акбаш авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша акча күчерү юлы белән Ташкичү авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта 2
Акбаш авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2023 елның 31
гыйнварынна 5 номерлы карары

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮНАМӘ) № ______

Акбаш авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И. А.и.
_______________________________________________________________________________
Адресы:
_________________________________________________________________
Гражданнар җыены карары нигезендә Акбаш торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча , Сезгә 2023 елның 1 февраленнән 25 мартына елга кадәр гражданнар җыены чараларын тормышка ашыру өчен 500 сум күләмендәге бер тапкыр түләнелә торган акчаны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
Банк получателя
БИК

Получатель
Сч. №
ИНН КПП
КБК
ОКАТО
Назначение платежа **самообложение граждан за 2023 год.**

Җитәкче __________________ __________________________________________
М. У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү линиясе** - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Белдерүнамә) № __________________
Акбаш авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча_________________ сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү турында
(*муниципаль берәмлек исеме*)

Түләүченең Ф.И. А.и.
__________________________________________________________
Адресы:
_______________________________________________________________________________
Кабул ителде «__» ________________ 20__ елда
________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзелмә төпсә (отрывной корешок) тутырыла һәм Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетында калдырыла.*